| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ЗАРЕЧЕНСК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2021 нче ел Яңа Зареченск авылы № 44

Совет карарына үзгәрешләр кертү турында
Яңа Зареченск авыл җирлеге
Баулы муниципаль районы
18.10.2019 ел № 118 «Яңа Зареченск авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше
һәм бюджет процессы турындагы
нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2019 ел № 479-ФЗ, «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 02.04.2020 № 103-ФЗ Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Яңа Зареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Баулы муниципаль районы Яңа Зареченское авыл җирлеге Советының 18.10.2019 ел №118 карары белән расланган Нигезләмәгә (10.12.2019 ел №125, 18.03.2020 ел №138, 08.06.2020 ел №146 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 статьяның 45 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының җирле бюджетка керүнең тулылыгын һәм үз вакытында булуын, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тота»;

14 статьяның 27 пунктына түбəндəге эчтəлекле тəкъдим өстəргə: «кредит (займ) буенча принципал йөклəмəлəрен үтəүне тəэмин итүче муниципаль гарантия кредит килешүендə (займ килешүендə) һəм (яисə) күрсəтелгəн муниципаль гарантияне бирү турындагы килешүдə кредитор (заемчы) йөклəмəлəрен үз ягыннан күрсəтелгəн кредит (займ) акчаларын максатчан файдалануны тикшереп тору шарты белəн бирелə.»;

26 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

26 статьяның 2 пунктындагы 3 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Əлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мəгълүматының рəсми порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3.Əлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченə керə.

4. Əлеге карарның үтəлешен контрольдə тотам.

Җирлек башлыгы, Яңа Зареченск
авыл җирлеге Советы Рəисе А.Р. Зəбирова